


- Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы “Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Мәчкәрә мәктәп- интернаты” дәүләт бюджет гомуми белем учреждениесе


# Нәниләр атналыгы



- Төзеде:I квалификацион категорияле башлангыч сыйныфлар укытучысы
- Хәлиуллина Диләрә Әрхәметдиновна



# Нәниләр атналыгы





# Юл хәләкәтенә китерә торган сәбәпләр:


-юлларның начар булуы

-транспорт төзек булмау

-юл йөрү кагыйдәләрен белмәү

- тротуарлар булмау

-зебра, светофор




# Беренче автомобиль



Никола Жозеф  Кюньо

Беренче тапкыр юл транспорты хәлакәте 1769 елда Парижда Кюньо ясаган пар казаны белән эшли торган автомобиль белән булган



1896 елның августында Англиядә 6 км /сәг белән бара торган машина җәяүлене бәрдерә.





Ел саен безнең илебездә 35 мең кеше һәлак була. Шуның 1500е балалар. Ә инде 20 мең бала төрле дәрәҗәдә тән җәрәхәтләре ала

Кайчандыр бик күптән урамнарда, юлларда атлылар гына йөргән. Бу чараны да транспорт дип йөрткәннәр



Иң беренче юл йөрү кагыйдәсе 2000 еллар элек Юлий Цезарь вакытында барлыкка килгән. Бу кагыйдәләр шәһәр юлында хәрәкәтне тәртипкә салырга ярдәм иткән.

Беркемгә дә сер түгел, авылларда юл билгеләре куелмаса да аларны белергә кирәк. Авылда да билгеләр куярлык урыннар күп. Чөнки анда да машиналар күп йөри. Шуңа күрә без кечкенәдән үк юлда йөрү кагыйдәләрен белергә тиешбез, юлда имин йөрүебез үзебездән тора. Чөнки кагыйдәне белмәгән балалар куркыныч хәлләргә күбрәк юлыгалар.



«Сак йөрегез зур юлларда»


Интелектуаль уен

# «Светофор»

Урамнарны күзәтеп,
Ваемсызны кисәтеп,
Чатта тора светофор,
Сакта тора светофор.

## «3 б а»

Җәяүле өчен юлда
Яхшы сукмак - “зебра”
Юк ла инде, хайван түгел,
Каралы-аклы ул юл.



# Юл хәрәкәтендә катнашучылар:



Йөртүче



Җәяүле



Пассажир

***Йөртүче*** – нинди дә булса транспорт чарасы белән идарә итүче кеше.

***Җәяүле*** – юлда транспортка катнашы булмаган һәм анда эш башкармый торган кеше.

***Пассажир***- йөртүчедән башка транспорт эчендәге кеше, шулай ук транспорт чарасына керүче (утыручы) яисә чыгучы (төшүче) кеше.





# 1



# “Юл йөрү  әлифбасы”





# ТАПКЫРЛАРГ
# А
# ТАБЫШМАК.





**АК ӨЧПОЧМАКЛЫ БИЛГЕ ҖӘЯҮЛЕГӘ КИҢӘШЧЕ. “КЫЮ АТЛА ЮЛ АРКЫЛЫ МИН БУЛГАНДА ӘЙДӘЛЕ!”**



**ҖӘЯҮЛЕ СУКМАГЫ.**







КЫЗЫЛ ТҮГӘРӘКТӘ КЕШЕ
“ӘЙТӘ КЕБЕК ШУЛ ХАКТА:
“ЮЛ ЮК МОНДА ҖӘЯҮЛЕГӘ,
ИКЕНЧЕ ЮЛДАН АТЛА!



ҖӘЯҮЛЕГӘ ЮЛ ЮК!







КЫЗЫЛ ТҮГӘРӘК ЭЧЕНДӘ БУ НИНДИ АП- АК ШАКМАК?



ЮЛ ЮК!





http://aida.ucoz.ru



АНДЫЙ БИЛГЕ БУЛГАН
ҖИРДӘ
ЙӨРЕП БУЛА “СӘПИДТӘ”.



**ВЕЛОСИПЕД ЮЛЫ**







**ЮЛДА БИК АЧЫКСАГЫЗ,**
**АШХАНӘНЕ ТАБАРГА**
**СЕЗГӘ ЯРДӘМГӘ КИЛЕР**
**КАЙСЫ БИЛГЕ, КЕМ ӘЙТЕР?**



**АШХАНӘ - ХЕЗМӘТ КҮРСӘТҮ БИЛГЕСЕ.**





http://aida.ucoz.ru



ЮЛДА ТУКТАП ЯЛ ИТӘРГӘ
УРЫН КИРӘК ҺӘРКЕМГӘ.
ҖАВАП ЭЗЛӘП АПТЫРАМА,
ТАНЫШ БИЛГЕ УЛ СИҢА.




ЯЛ ИТҮ УРЫНЫ








# “Мозаика” тукталышы





# Юл аркылы чыкканда ничек карарга?

1. Башта уңга, аннан сулга;
2. Башта сулга, аннан уңга;
3. Күзләрне йомып, чабарга.






Җәяүлеләр кайдан йөрергә тиешләр?

1.автомагистральдән;

2. тимер юлдан;

3. тротуардан.






Тротуар булмаган урыннан ничек барырга?

1.хәрәкәткә каршы;

2. хәрәкәт уңаена

3. юл уртасыннан






Юл хәрәкәтен көйләүче кем дип атала?

1.инженер

2. инспектор

3. энергетик






Җәмәгать транспортында билет сатучы кем дип атала?

1.кондуктор

2. директор


3. кондитер





Җәмәгать транспортында билетсыз йөрүче ничек атала?

1. «карга»
2. «куян»
3. «кунак»



# “Мозаика” тукталышы











# “Ярый-ярамый” тукталышы





Ничә яшьтән баланы алгы утыргычка утыртып йөрергә ярый?

**12 яшьтән**






# Пассажирлар белергә тиешле кагыйдәләр:

Пассажирлар тиеш:

-Утыру һәм төшүне тротуар ягыннан яисә юл кырыеннан һәм фәкать транспорт чарасы туктап беткән-нән соң гына башкарырга;

-Куркынычсызлык каешларын эләктерергә;





# Пассажирлар белергә тиешле кагыйдәләр:

## Пассажирларга тыела


-

-Хәрәкәт вакытында урыныннан торып йөрү;

-Хәрәкәт вакытында йөртүчегә комачаулау;

-Хәрәкәт вакытында транспорт чарасының ишекләрен ачу;

-Кычкырып сөйләшү; музыка тыңлау; һ.б.



# “Велосипедта” тукталышы














***Велосипед йөртүчегә тиеш:***

-велосипедчының яше 14тән ким булса, аңа ишегалдында гына йөрергә рөхсәт ителә;

-велосипедның тормоз тоту һәм тавыш сигналы җайланмасы төзек булырга тиеш;

-велосипед размеры баланың буй озынлыгына туры килергә тиеш;






***Велосипед йөртүчегә тыела:***

-рульгә бер кул белән генә тотынып бару;

-янәшәдә велосипедчы юлы булганда машина юлыннан бару;


-трамвай хәрәкәте булган юлларда һәм хәрәкәт өчен полоса саны бу юнәлештә бердән артык булган юлларда сулга яки кирегә борылу;

-озынлыгы һәм киңлеге 0,5 метрдан артыгракка чыгып торган яисә идарә итүгә комачаулык ясый торган йөк ташу.





“Командирлар бәйгесе”





# “Артык сүз” тукталышы


1.Җәяүле

2.пассажир

3.йөртүче

4.Өйдә йоклап ятучы

Өйдә йоклап ятучы –
ул юл хәрәкәтендә катнашучы түгел






# “Артык сүз” тукталышы

1.Машинист

2.Пилот

3.Пассажир

4. Шофёр



Пассажир –
ул транспорт белән идарә итүче түгел.



# “Артык сүз” тукталышы


1.Алдаучы

2.Кисәтүче

3.Күрсәтмә

4. Тыючы

Алдаучы –
андый юл билгесе юк.





# “Артык сүз” тукталышы


1.Парк

2. Юл

3.Стадион

4. Балалар мәйданчыгы


Юл –
уен һәм ял итү урыны түгел






# “ Яшерен сүз” тукталышы

**АВТОСПОРТТРАН**
**АВТОТРАНСПОРТ**






# “Күңелле автомобиль”



# “Күңелле автомобиль”

Елганы аркылы чыкканда автомобильнең нинди детале ярдәмгә килә?






**Мост - күпер**


# “Күңелле автомобиль”

Өйдә ут сүнгәндә автомобильнең нинди детале ярдәмгә килә?



**Свеча - шәм**









# “Күңелле автомобиль”

Автомобильнең нинди җайланмасы белән өй ишеген биклибез?





**Замок - йозак**






# “Күңелле автомобиль”

Автомобильнең нинди җайланмасы ярдәмендә чалбарны кысып куябыз?





**Ремень - каеш**






# “ Сүз яса ” тукталышы

## АВТОТРАНСПОРТ

| | | |
|---|---|---|
| СПОРТ | СОР | СТАРТ |
| ПОРТ | НОС | РАНА |
| РОТ | СОН | АВТОР |
| СПОР | РОТА | АВТО |
| ТРОС | СОРТ | |
| ТРАНСПОРТ | | |
| ТОРТ | НОРА | СОВА |
| ВАТА | ТОВАР | ПОСТ |






# САК ЙӨРЕГЕЗ ЮЛЛАРДА!

*Сак йөрегез зур юлларда*
*Юлыкмый хәвефләргә.*
*Хәерле юл барчагызга,*
*Киләчәк гомерләргә.*
*Сак йөрегез зур юлларда*
*Юлыкмый хәвефләргә.*
*Куелмасын һәйкәлләр дә*
*Озын юл буйларында.*

